РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
ГЛАВА КИЛЬДЕБЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422071, Республика Татарстан, Сабинский район,

с.Кильдебяк, ул. Кооперативная, 20а

тел. (84362) 45-5-50

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КИЛДЕБӘК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

422071, Татарстан Республикасы, Саба районы,

Килдебәк авылы, Кооперативная урамы, 20а йорт

тел. (84362) 45-5-50

e-mail: Kilb.sab@tatar.ru

18.10.2024 № 3

**КАРАР**

« Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлегенең Мәртен торак пункты гражданнарның үзара салым акчаларыннан файдалану турында җыенын билгеләү турында »

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Саба муниципаль берәмлеге муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлегенең муниципаль берәмлек башлыгы карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлегенең Мәртен торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын ТР, Саба районы, Мәртен авылы, Киров урамы,1 йорта урнашкан Мәртен авыл клубында 2024 елның 29 октябрендә 18.00 сәгатькә билгеләргә:.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга::

Сез Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлегенең Мәртен торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( туфрак эшкәртү, комлы нигез салу, вак таштан нигез салу, юл кырыйларын төзү, су үткәрү торбаларын урнаштыру, Мәртен торак пунктындагы килешү буенча эшләр өчен түләү)

« ӘЙЕ» "КАРШЫ"

3. Әлеге карарны " Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru адрес буенча Саба муниципаль районының рәсми сайтында, hhttp: / / saby. tatarstan. ru / kildebiak адресы буенча җирлекнең рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларында 10 көн дәвамында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга:

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Килдебәк авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Заһидуллин